# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Бари Рәхмәт**

Бари Рәхмәт 1897 елның 29 маенда элекке Урал губернасының Гурьев өязе Жилая Коса дигән поселогында туа. Башлангыч белемне мәдрәсәдә ала. 1914 елда «Бәйрәм котлы булсын» исемле беренче шигыре дөнья күрә.

Бөек Октябрь революциясеннән соң Б. Рәхмәт 1918-1921 елларда Казандагы татар запасной батальонында хезмәт итә.

1921 елда армия сафыннан демобилизацияләнгәч, Б. Рәхмәт туган якларына кайта һәм 1932 елга кадәр шунда яши. 1939 елдан башлап, «Чаян» һәм «Совет әдәбияты» журналларында аның сатирик һәм лирик шигырьләре яңадан күренә башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елда, Б. Рәхмәт фронтка китә. Аның «Исән булсак, бетмәбез», «Без кайтырга чыктык», «Бармагыңа акча түлим», «Әби белән бабушка кебек шигырьләре матур үрнәкләре булып санала.

Бари Рәхмәт үзенең шигъри сәләте тәмам ачылып җиткәндә, 1957 елның 26 маенда кинәт вафат була. (120 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Нури Арсланов**

Нури Арсланов 1912 елның 19 сентябрендә Казахстанның Кызылъяр шәһәрендә туган. 1928 елда Күкчәтау шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлый, аннары Казанга килеп, сәнгать техникумының рәсем бүлегендә укый.

1933 елның сентябреннән Нури Арсланов яңадан Казанда — балалар журналы «Пионер» (хәзерге «Ялкын») һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакцияләрендә рәссам вазифаларын башкара. 1946 елдан ул СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Сугыштан соң Нури Арсланов ун елга якын «Совет Татарстаны» редакциясендә — рәссам булып эшли. Шагыйрьнең күп кенә лирик шигырьләре композиторлар тарафыннан музыкага салынган. «Республикам минем», «Казан кызы», «Үрдәкләрем-дүдәкләрем» кебек җырларын татар җыр сәнгатенең гүзәл үрнәкләре исәбенә кертергә мөмкин.

Нури Арсланов — бай шигъри мирас калдырган шагыйрь. 1985 елда «Иделем-илем» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен ул Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Нури Арсланов 1991 елның 12 апрелендә вафат була. (123 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Шәйхи Маннур**

Шәйхи Маннур 1905 елның 15 гыйнварында элекке Казан губернасы Мамадыш өязе Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында һәм күрше авылдагы мәдрәсәдә ала. Мамадыш шәһәрендәге педагогия курсларында укый.

1927-1929 елларда армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Донбасс якларына китеп, металлургия заводында укытучы-ликбезчы хезмәтендә була. Ул «Колчеданлы таулар өстендә», «Чуен ташкыннар», «Бетончылар җыры» исемле беренче поэмаларын һәм шигырьләрен яза.

1960-1970 нче еллар әдәби хәрәкәтендә Шәйхи Маннур прозаик буларак катнаша. Ул иҗат иткән проза әсәрләре арасында иң күренеклесе – «Муса» романы. Үзе исән чагында аның дүрт дистәгә якын китабы дөнья күрә. Алар арасында махсус балаларга адресланганнары да бар.

Шәйхи Маннур 1980 елның 10 июнендә Казанда вафат була. Маннур 1957 елда туган авылында үз акчасына китапханә салдыра һәм 100 данә китап бүләк итеп бирә. (123 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Нәби Дәүли**

Нәби Дәүли 1910 елның 1 июнендә Әлки районының Яңа Камка авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Бик яшьли ятим калып, Царицын балалар йортында тәрбияләнгән. Шунда Донбасс металлургия заводына эшкә җибәрелгән. 1931 елда Донецкида чыга торган «Пролетар» газетасы редакциясенә күчә. 1932-1934 елларда армия сафларында хезмәт итә. Аннан соң, Казанга кайтып, Яшь сталинчы газетасы редакциясендә эшли.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, әмма 1941 елның августында ул фашистлар кулына әсир төшә. 1945 елның апрелендә ул берничә иптәше белән лагерьдан кача, Совет Армиясенә кушыла һәм сугышны фронтта тәмамлый.

Шагыйрьнең сугышка кадәр үк “Бәхет”, “Ал чәчәк”, “Уйлар”, “Кырык шагыйрь” дигән китаплары дөнья күрә. Сугыштан соң “Яшәү белән үлем арасында” һәм “Җимерелгән бастион” дигән повестьлары, “Минем танышларым”, “Тамгалы бүре” дигән хикәяләр басылып чыга.

Шагыйрь 1989 елда вафат. (123 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Салих Баттал**

Салих Баттал 1905 елның 5 августында элекке Казан губернасы Спас өязе Зур Тигәнәле авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Алты яшендә үзлегеннән укырга-язарга өйрәнә, соңыннан күрше авыл мәдрәсәсендә укый. Фабрика янындагы татар клубы стена газетасында аның В.И.Ленин үлеменә багышланган беренче шигыре дөнья күрә. Тиздән шигырьне Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Эшче» газетасында да бастыралар.

1924—1926 елларда Салих Баттал татар-башкорт эшче яшьләренең Мәскәүдәге ике еллык гомуми белем курсларында укый.

Салих Баттал — очучы. 1927 елда Салих Баттал Кызыл Армиясе хәрби һава көчләрене мәктәбенә укырга керә. Ватан сугышы чорында Салих Баттал Хәрби Һава Көчләренең Тын Океан флотында хәрби очучы булып хезмәт итә. 1942 елда Сугыш елларында әдип патриотик рухтагы шигырьләр һәм «Капитан Гастелло» исемле поэмасын яза.

Салих Баттал 1995 елның 12 мартында 89 яшендә өендә янгыннан үлә. (125 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Фатих Хөснетдинов**

Фатих Хөснетдинов 1908 елның 3 февралендә Русиянең элекке Казан губернасы Лаеш өязе Олы Мәтәскә дигән авылда туа. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә ала. 1924-1929 елларда Казандагы М.Вахитов исемендәге мәктәптә укый. 1927-1930 еллар арасында «Безнең юл» журналы, «Авыл яшьләре», «Яңалиф», «Атака» журналлары битләрендә дистәләгән лирик шигырьләре дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы чорында Ф.Хөсни каләм көчен фашизмга каршы көрәшкә юнәлтә. «Йөзек кашы» исемле повесте аеруча игътибарга лаеклы.

Ватан сугышыннан соңгы елларда «Җәй башы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Мәйдан», «Без яшь идеккебек психологик пландагы повесть һәм романнарын иҗат итә. «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» дигән повесте өчен Ф.Хөсни 1972 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Ул озакка сузылган каты авырудан соң 1996 елның 19 маенда Казанда вафат була. (120 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Әхмәт Фәйзи**

Әхмәт Фәйзи 1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә туа. Әхмәт башта мәдрәсәдә укый, аннары Уфаның рус-татар мәктәбендә һәм татар гимназиясендә белем ала. Урта мәктәпне тәмамлагач, аны Ырынбур Шәрык педагогия институтына укырга җибәрәләр. Ләкин 1921—1922 еллардагы ачлык афәте Әхмәткә институтны тәмамларга мөмкинлек бирми. 1922 елның декабрендә ул Урта Азиягә китә һәм 1924 елга кадәр Төрекмәнстанда укытучы булып эшли. 1924 елда яңадан Уфага кайта, тәрбияче һәм укыту бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

1924 елның ахырыннан башлап, Фәйзи берничә ел Донбасста татар шахтерлары арасында укыту эшләре алып бара. 1931 елда Мәскәүгә күчеп, язучы сыйфатында башкалада яшәп уздыра. Бөек Ватан сугышы башлангач фронтка китә һәм Волхов, Карелия, Дүртенче Украина фронтларында чыккан «Сталин байрагы» газетасында хәрби мөхбир булып хезмәт итә. Әхмәт Фәйзи 1958 елның 11 августында вафат була. (123 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Сәйфетдин Фәттах улы Кудашев**

Сәйфетдин Фәттах улы Кудашев 1894 елның 21 сентябрендә Башкортстанның Келәш авылында, хәзер Чишмә районы, крестьян гаиләсендә туа. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1913 елда Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафури йогынтысында яза башлый. 1916 елда юмористик шигырьләре Ырынбурда чыккан «Кармак» журналында даими басылып тора.

1929 елда Татарстан һәм Башкортстан әдәбиятларында "Җидегәнчелек"кә каршы көрәш сылтавы белән репрессияләр башлана.

Ул вакытлыча Уфадан китеп бара, Кыйгы районына татарча газет оештырырга алына. Басмада аның күпсанлы мәкаләләре басыла. Шунда яшәп, күмәкләштерү турында бәян иткән, булачак «Кушкаен» романына материал әзерли. Соңыннан, күпчелек «җидегәнчеләр» кичерелә, шул исәптән Сәйфи Кудаш та. 1935 елда ул СССР язучылар берлегенә алына.

Гомеренең соңгы елларын да Сәйфи Кудаш тыныч үткәрми. Аның өстенә татар һәм башкорт язучыларын кырган 1937 ел сәяси репрессияләре өчен җаваплылыкны аудару шаукымы күзәтелгән. (122 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Ибраһим Мингазиев**

Ибраһим Мингазиев 1907 елның 4 февралендә хәзерге Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы Иске Карамалы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1919-1924 елларда ул Тәтештәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда урта белем ала, шунда комсомол сафына басып, актив җәмәгать эшчәнлеген башлый. Аның беренче әдәби әсәрләре — лирик парчалары «Көлмә, Идел!», «Соңгы чаң» матбугатта 1929 елда басылып чыга. 1943 елдан башлап җиңү көннәренә кадәр Ибраһим Гази «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби мөхбир булып хезмәт итә.

Ибраһим Газиның эпик жанрдагы иң зур әсәре — «Онытылмас еллар» трилогиясе. Бу әсәрне әдип гомере буе эшли.

1988-1989 елларда әсәргә нигезләнеп Татарстан телевидениесендә күп серияле телефизион фильм төшерелгән.

Язучылык хезмәте өчен ул шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнә. Ибраһим Гази 1971 елның 21 февралендә Казанда вафат була. (121 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Шәрәф Мөдәррис**

Шәрәф Мөдәррис 1919 елның 1 ноябрендә хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне үз авылында ала, җидееллык мәктәпне күрше Мунчәли авылында тәмамлый һәм 1935 елда Казанга килеп, педагогика институты каршындагы рабфакка укырга керә. 1937 елда ук инде «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

1941 елда Шәрәф Мөдәррис Кызыл Армия сафына алына. Шул ук елның җәендә Смоленск өлкәсендә барган сугышларның берсендә Ш. Мөдәррис яралана. 1942 елда ул яңадан сугышка китә, минометчы-солдат булып сугыша. «Тупчы Вәһап» исемле күләмле эпик поэмасында шагыйрь үзе аралашып яшәгән гади совет кешеләренең хисләрен, сугыштагы батырлыкларын, аларның гуманизмын, фашизмга үтергеч нәфрәтләрен тасвирлый.

Армиядән кайткач, төрле газета редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Шәрәф Мөдәррис шигъри талантының ачылып җиткән чорында, 1963 елның 28 апрелендә вафат була. (123 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Гәделша шарлавыгы.**

Гаделша шарлавыгы - Баймак районындагы, Ирәндекнең көнчыгыш тармагы булган Яманташ тавында аккан кечкенә елга шарлавыгы. Гәделша Башкортостанда иң биек шарлавык булып санала. Атамасы шул ук исемдәге авыл хөрмәтенә бирелгән. Ләкин еллар узган саен Гәделша авылы ташландык хәлгә килеп, юкка чыккан.

Өч киртләчле шарлавыкның иң югары киртәсе бер метрдан артыграк, икенче һәм өченче киртләче җидешәр метрга җитә. Нәтиҗәдә шарлавыкның гомуми биеклеге-якынча 15 метр.

Гаделша шарлавыгы үзенең искиткеч матурлыгы белән генә түгел, уникаль флора һәм фаунасы белән дә кешеләрне җәлеп итә. Шарлавык территориясендә "Башкортстанның Кызыл китабы"на кертелгән үсемлекләрне, кошларны, хайваннарны очратырга мөмкин . Апрель ахыры һәм май башында, кар суларының күпләп кушылуы сәбәпле, су чыгымы арта. Салкын судан һәм текә кыя-ташлардан килгән саф һава, күңелгә нииндидер рәхәтлек биреп, рухландыра. Шарлавык һаман да үзенең матурлыгы белән килүчеләрне сөендерә. (121 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Караидел.**

Башкортстанда зурлыгы буенча икенче урында торган Караидел елгасы, тәрҗемә иткәндә «Кара елга» дигәнне аңлата. Кара дип исем бирелүе юкка түгел. Зур тирәнлекләрнең үтә күренмәле сулары шулай карачкыл төс бирә. Елга Чиләбе өлкәсенең төньяк-көнбатышындагы Уфа күленнән ага. Башта төньякка таба хәрәкәт итә аннары юнәлешен төньяк-көнбатышка үзгәртә, ә аннары, борылып, Башкортстан территориясе буйлап ага. Биредә елга үзенең беренче зур кушылдыгы – Әй елгасын ала.

Караиделнең текә ярлары, куе катнаш урманнар белән капланган. Елга суының чисталыгы, үтә күренмәлелеге һәм балыкның күплеге белән гаҗәпләндерә. Тәҗрибәле балыкчылар биредәге суларда җәен, чуртан, хариус балыклары таба ала.

Караидел елгасы – Башкортстанның иң матур һәм тыныч елгаларының берсе. Елганың бер як яры урманнар белән капланган, икенче ягында күбрәк ачык кырлар, яланнар ята. Бу- табигать сөючеләр өчен чын матурлык һәм ял итү урыны. (122 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Асылыкүл.**

Республикабызда иң зур күл Дәүләкән районында - ул Асылыкүл. Аның буе сигез, киңлеге –биш километр. Бу күлне безнең якның диңгезе дияргә мөмкин. Аның ярларында сирәк очрый торган үсемлекләрнең байтак төре үсә. Күл тирәсендәге куакларда күп төрле кошлар оя кора, аларның кайберләре бик аз калган.

Асылыкүл кайчандыр гаять зур мәйданда убылып төшкән бирдә барлыкка килгән. Аның суы бераз тозлырак. Күлнең төньяк-көнчыгыш өлешендә су төбе ләмле, аны дәвалау өчен файдаланалар.

Асылыкүлдә балык күп. Кайчан килсәк тә, без һәрвакыт биредә балыкчыларны күрә идек. Шунысы кызык, күптән түгел монда энә балык күренә башлады. Бу балык диңгездә яши. Моннан берничә ел элек ала балыкларны тукландыру өчен күлгә диңгездән су бөрчәләре алып килеп җибәргәннәр иде. Алар белән бергә энә балык уылдыгы да эләккән булган, күрәсең. (119 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Агыйдел.**

Башкортстанның иң озын булган Агыйдел елгасы 1430 километрга сузылган һәм бөтен республиканы диярлек кисеп үтә.

Елга атамасының килеп чыгышы ике гипотеза белән әйләндереп алынган. Беренче версия «якты» һәм «ак» эпитетлары белән бәйле. Икенче гипотеза буенча, атама елга суында известь кушылмалары булу аркасында барлыкка килгән аксыл төс белән бәйле дип раслый. Агыйдел Кама елгасына коя һәм Каспий диңгезе бассейнына карый. Елга ярлары буйлап зур шәһәрләр: Белорет, Уфа һәм Агыйдел җәелеп ята.

Яр буе табигатенең матурлыгы сокландыра. Куе урманнарда гаҗәпләндергеч күренешләр – поши, кабан һәм кыр кәҗәләренең көтүләрен очратырга мөмкин.

Агым уңаена бераз түбән төшсәң, урман мозаикасы бераз үзгәрә башлый, һәм монда гөлҗимеш агачына охшаш куаклар киң тарала. Елга ярларында таллар һәм тирәкләр гөрләп чәчәк ата. Сазлыклы аулак урыннарда җиләк аланнары җәелеп ята, ә куаклар арасында, көртлекләр үз ояларын җайлап куйганнар. (128 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Яман елга**

Яман Елга - Караидел елгасының сул кушылдыгы. Аның атамасы "Начар елга"дип тәрҗемә ителә. Бәлки, моның сәбәбе язгы елга котыруыннан булгандыр. Ташу вакытында ул җир астыннан күтәрелә, юлындагы бөтен нәрсәне юып төшерә. Яман – Елга - республиканың иң мәшһүр җир асты елгаларының берсе, ул 40 чакрым буена җир астында ага, аннары Кызыл Чишмә булып килеп чыга. Елганың гомуми озынлыгы якынча 60 километр. Яман - Елга чокырына агып төшкән бөтен су, җир астына кереп югала. Берничә дистә километр буена Яман-Елга җир астында адашып йөри, ә җир өстендә коры җир юлы сузыла. Яман-елга буйларында бик күп коры җирләр, сусыз чокырлар ята. Елга 16 чакрымнан соң җир өстенә чыга. Сулыкны бик күп вак инешләр, карст чишмәләре тулыландыра. Елгада форель һәм Европа хариусы кебек югалып баручы балык төрләре бар. (123 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**